ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

13.11.2019　　　　с. Коргуза　　　　04

**Гражданнарның үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2019 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2019 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә.

1 этап: Карагуҗа авылы, Первомайская урамы (11нче йорттан 28 нче йортка кадәр), Садовая урамында яшәүчеләр;

2 этап: Карагуҗа авылы, Центральная урамы (1,3,5,7,9 номерлы йортлар һәм 11 нче йорттан 56 нчы йортка кадәр);

3 этап: Карагуҗа авылы, Молодежная, Боевая урамнары, Центральная урамы, 2,4,6,8,10 номерлы йортлар;

4 этап: Карагуҗа авылы, Заречная, Набережная, Пролетарская урамнары

5 этап: Карагуҗа авылы, Октябрьская урамы, Первомайская урамы (1 нче йорттан 10 нчы йортка кадәр)

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы?:

- Урамнарда суүткәргечне ремонтлау: Карагуҗа авылы, Молодежная урамы - 293м., Пролетарская һәм Боевая урамнары- 760м., су башнясыннан 1 Май урамы 2 нче йортка кадәр - 216м.

« ӘЙЕ» «ЮК»

8. Гражданнар җыеннарын уздырырга:

1 этап: Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан, мәктәп гаражы янында;

2 этап: Карагуҗа авылы, Центральная урамы буенча кибет янындагы чатта;

3 этап: Карагуҗа авылы, иске ФАП янында;

4 этап: Карагуҗа авылы, Набережная, 15 нче йорт янында (Бочков А.И.)

5 этап: Карагуҗа авылы, Октябрьская урамы, 12 нче йорт (Гурьянова А.Н.) янында

9. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Югары Ослан муниципаль районының**
**Карагуҗа авыл җирлеге Башлыгы С.А.Сакин**